**ЗАКОН**
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

**О патриотическом воспитании граждан в Республике Татарстан**

Принят
Государственным Советом
Республики Татарстан
23 ноября 2023 года

Статья 1. **Предмет регулирования настоящего Закона**

1. Настоящий Закон регулирует отношения, возникающие в сфере патриотического воспитания граждан в Республике Татарстан (далее – патриотическое воспитание), определяет цель, принципы и задачи патриотического воспитания.

2. Законодательство Республики Татарстан о патриотическом воспитании основывается на соответствующих положениях Конституции Российской Федерации, Конституции Республики Татарстан, федеральных законов, иных нормативных правовых актов Российской Федерации и состоит из настоящего Закона, других законов Республики Татарстан и принимаемых в соответствии с ними нормативных правовых актов Республики Татарстан.

Статья 2. **Основные понятия, используемые в настоящем Законе**

1. Для целей настоящего Закона под патриотическим воспитанием понимается целенаправленная деятельность органов государственной власти Республики Татарстан, органов местного самоуправления, социально ориентированных некоммерческих организаций, осуществляющих деятельность в сфере патриотического, в том числе военно-патриотического, воспитания граждан, и иных субъектов патриотического воспитания по формированию у граждан патриотического сознания, верности Родине, готовности к выполнению гражданского долга и конституционных обязанностей по защите Отечества, уважения к отечественной истории.

2. Иные понятия, используемые в настоящем Законе, применяются в значениях, установленных федеральным законодательством и законодательством Республики Татарстан.

## Статья 3. **Цель, принципы и задачи патриотического воспитания**

1. Основной целью патриотического воспитания является формирование у граждан духовно-нравственных и социальных ценностей, гражданственности, верности конституционному и воинскому долгу, ответственности и дисциплинированности.

2. Принципами патриотического воспитания являются:

1) адресный подход в работе с гражданами;

2) системность, организация взаимодействия органов государственной власти Республики Татарстан с иными субъектами патриотического воспитания;

3) учет национальных, этнокультурных, конфессиональных особенностей граждан при организации деятельности по патриотическому воспитанию;

4) непрерывность и преемственность в патриотическом воспитании граждан;

5) открытость и независимость в оценке результатов реализации мер, направленных на патриотическое воспитание;

6) формирование отношения к семье как основе российского общества.

3. Основными задачами патриотического воспитания являются:

1) воспитание граждан в духе уважения к Конституции Российской Федерации, Конституции Республики Татарстан, соблюдения законности;

2) формирование у граждан уважения к культурному, историческому прошлому и традициям Российской Федерации, Республики Татарстан, готовности к служению Отечеству, его защите, добросовестному выполнению гражданского, профессионального и воинского долга;

3) привитие гражданам чувства гордости и уважения к государственным символам Российской Федерации, государственным символам Республики Татарстан;

4) развитие системы патриотического воспитания, повышение престижа государственной службы, совершенствование подготовки граждан к службе в рядах Вооруженных Сил Российской Федерации;

5) развитие добровольческой (волонтерской) деятельности;

6) формирование у граждан потребности в духовно-нравственном развитии и уважительного отношения к старшему поколению, обеспечение связи между поколениями, проявление заботы о пожилых и близких людях, укрепление института семьи и сохранение традиционных семейных ценностей;

7) развитие дружественных связей между народами, создание условий для обеспечения межнационального и межконфессионального согласия, противодействия проявлениям экстремизма.

## Статья 4. **Государственная политика Республики Татарстан в сфере патриотического воспитания**

1. Государственная политика Республики Татарстан в сфере патриотического воспитания представляет собой совокупность мер, осуществляемых органами государственной власти Республики Татарстан во взаимодействии с органами местного самоуправления и иными субъектами патриотического воспитания,

направленных на патриотическое воспитание.

2. Реализация государственной политики Республики Татарстан в сфере патриотического воспитания осуществляется в следующих формах:

1) нормативно-правовое регулирование в сфере патриотического воспитания;

2) научное и методическое сопровождение системы патриотического воспитания, распространение наиболее успешных и перспективных форм и методов работы по патриотическому воспитанию;

3) межведомственное взаимодействие и развитие государственно-общественного партнерства в сфере патриотического воспитания;

4) разработка и внедрение программ, методик по организации и проведению патриотического воспитания детей и молодежи и повышению их мотивации к службе Отечеству, интереса к изучению истории Отечества;

5) подготовка специалистов в сфере патриотического воспитания;

6) информационное обеспечение патриотического воспитания;

7) создание и сохранение историко-краеведческих и мемориальных музеев, установление и благоустройство памятников, обелисков, стел, других мемориальных сооружений, объектов, увековечивающих дни воинской славы и памятные даты Российской Федерации, памятные даты Республики Татарстан, организация выставок, установление на местах воинской славы мемориальных знаков;

8) разработка туристских маршрутов по историческим местам Республики Татарстан;

9) обеспечение условий для прохождения гражданами допризывного и призывного возрастов подготовки к службе в рядах Вооруженных Сил Российской Федерации;

10) организация и развитие системы взаимодействия образовательных организаций с организациями ветеранов, музеями боевой славы, а также с ветеранами Великой Отечественной войны, боевых действий, военной службы;

11) оказание поддержки деятелям искусства и литературы в создании произведений патриотической направленности;

12) организация и проведение торжественных и памятных мероприятий, посвященных дням воинской славы и памятным датам Российской Федерации, памятным датам Республики Татарстан;

13) поддержка общественных проектов в сфере патриотического воспитания.

### Статья 5. **Субъекты патриотического воспитания**

Субъектами патриотического воспитания являются:

1) органы государственной власти Республики Татарстан и подведомственные им организации;

2) органы местного самоуправления и подведомственные им организации;

3) образовательные и научные организации;

4) государственные и муниципальные организации культуры, искусства и кинематографии;

5) государственные и муниципальные организации в сфере молодежной

политики, физической культуры и спорта;

6) социально ориентированные некоммерческие организации, осуществляющие деятельность в сфере патриотического, в том числе военно-патриотического, воспитания граждан (далее – некоммерческие организации);

7) общественно-государственные организации, организации ветеранов, поисковые объединения и иные общественные объединения патриотической направленности;

8) государственные и муниципальные средства массовой информации;

9) центры патриотического воспитания;

10) граждане Российской Федерации, чей авторитет, патриотизм и верность своему гражданскому, профессиональному и воинскому долгу стали побудительным примером и образцом для подражания.

Статья 6. **Полномочия органов государственной власти Республики Татарстан в сфере патриотического воспитания**

1. К полномочиям Государственного Совета Республики Татарстан относятся:

1) законодательное регулирование отношений в сфере патриотического воспитания;

2) осуществление контроля за соблюдением и исполнением законов Республики Татарстан в сфере патриотического воспитания;

3) осуществление иных полномочий, предусмотренных федеральным законодательством и законодательством Республики Татарстан.

2. К полномочиям Главы (Раиса) Республики Татарстан относятся:

1) издание нормативных правовых актов в сфере патриотического воспитания;

2) обеспечение координации деятельности органов исполнительной власти Республики Татарстан с иными государственными органами, органами местного самоуправления и иными субъектами патриотического воспитания;

3) образование Координационного совета по патриотическому воспитанию граждан в Республике Татарстан (далее – Координационный совет), утверждение положения о Координационном совете и его состава;

4) осуществление иных полномочий, предусмотренных федеральным законодательством и законодательством Республики Татарстан.

3. К полномочиям Кабинета Министров Республики Татарстан относятся:

1) издание нормативных правовых актов в сфере патриотического воспитания;

2) определение основных направлений государственной политики Республики Татарстан в сфере патриотического воспитания;

3) утверждение государственных программ Республики Татарстан в сфере патриотического воспитания;

4) организация оказания методической помощи органам местного самоуправления в сфере патриотического воспитания;

5) оказание содействия и поддержки некоммерческим организациям в сфере патриотического воспитания;

6) осуществление иных полномочий, предусмотренных федеральным законодательством и законодательством Республики Татарстан.

4. К полномочиям органа исполнительной власти Республики Татарстан, осуществляющего государственное управление в сфере образования, относятся:

1) осуществление мер, направленных на патриотическое воспитание обучающихся в образовательных организациях;

2) взаимодействие с общественными объединениями патриотической направленности по вопросам реализации мероприятий в сфере патриотического воспитания;

3) организация и проведение мероприятий, направленных на формирование патриотического сознания обучающихся;

4) организация и проведение среди обучающихся олимпиад и конкурсов по патриотическому воспитанию;

5) обеспечение получения начальных знаний по основам военной службы обучающимися в общеобразовательных организациях;

6) организация проведения подготовки по основам военной службы обучающихся в образовательных организациях, реализующих образовательные программы среднего общего образования или среднего профессионального образования;

7) содействие развитию в образовательных организациях краеведческого движения, исследовательской, культурно-просветительской работы по изучению историко-культурного наследия Республики Татарстан;

8) осуществление иных полномочий, предусмотренных федеральным законодательством и законодательством Республики Татарстан.

5. К полномочиям органа исполнительной власти Республики Татарстан, осуществляющего государственное управление в области молодежной политики, относятся:

1) повышение уровня патриотической, политической и гражданской активности, зрелости молодежи;

2) усиление роли гражданско-патриотического воспитания в формировании ценностных ориентиров молодежи;

3) развитие системы патриотического воспитания молодежи, национального самосознания и толерантности в молодежной среде;

4) содействие развитию добровольческой (волонтерской) деятельности в Республике Татарстан;

5) организация и проведение мероприятий патриотической направленности;

6) осуществление иных полномочий, предусмотренных федеральным законодательством и законодательством Республики Татарстан.

6. К полномочиям органа исполнительной власти Республики Татарстан, осуществляющего государственную политику и регулирующего отношения в сфере культуры, искусства, кинематографии, относятся:

1) организация проведения мероприятий, посвященных историческим событиям и памятным датам Российской Федерации и Республики Татарстан;

2) организация, в том числе установление порядка проведения, фестивалей, конкурсов, выставок, кинофестивалей, творческих семинаров, тематических встреч со зрителями и иных мероприятий в сфере патриотического воспитания;

3) участие в российских и международных выставках, конференциях,

фестивалях и конкурсах в сфере патриотического воспитания, организация выставок на патриотическую тематику;

4) проведение конкурса на лучший музей (музейную экспозицию), посвященный увековечению памяти защитника (защитников) Отечества и совершенных им (ими) подвигов;

5) осуществление иных полномочий, предусмотренных федеральным законодательством и законодательством Республики Татарстан.

7. К полномочиям органа исполнительной власти Республики Татарстан, осуществляющего государственное управление и деятельность в области физической культуры и спорта, относятся:

1) организация физкультурно-оздоровительных спортивных мероприятий в целях повышения уровня физической подготовленности всех возрастных групп населения Республики Татарстан;

2) пропаганда военно-прикладных видов спорта;

3) организация реализации Всероссийского физкультурно-спортивного комплекса «Готов к труду и обороне» (ГТО) для всех возрастных групп населения Республики Татарстан;

4) осуществление иных полномочий, предусмотренных федеральным законодательством и законодательством Республики Татарстан.

8. К полномочиям органа исполнительной власти Республики Татарстан, осуществляющего полномочия по вопросам государственного управления в сфере печати и массовых коммуникаций, относятся:

1) организация освещения в средствах массовой информации мероприятий в сфере патриотического воспитания;

2) организация издания и распространения книг и печатной продукции, способствующих формированию патриотизма;

3) организация и проведение журналистских, творческих конкурсов на патриотическую тематику;

4) осуществление иных полномочий, предусмотренных федеральным законодательством и законодательством Республики Татарстан.

9. К полномочиям органа исполнительной власти Республики Татарстан, осуществляющего функции по государственному управлению в сфере туризма, относятся:

1) оказание содействия в разработке туристских маршрутов по историческим местам Республики Татарстан;

2) осуществление иных полномочий, предусмотренных федеральным законодательством и законодательством Республики Татарстан.

### Статья 7. **Участие органов местного самоуправления в патриотическом воспитании**

1. Органы местного самоуправления вправе участвовать в деятельности по патриотическому воспитанию в пределах полномочий, установленных федеральным законодательством.

2. Органы местного самоуправления вправе утверждать муниципальные

программы, содержащие мероприятия в сфере патриотического воспитания.

Статья 8. **Координационный совет**

1. В целях совершенствования взаимодействия органов исполнительной власти Республики Татарстан, иных государственных органов, органов местного самоуправления, а также иных субъектов патриотического воспитания создается Координационный совет.

2. Координационный совет образуется Главой (Раисом) Республики Татарстан и является консультативно-совещательным органом.

3. В состав Координационного совета включаются депутаты Государственного Совета Республики Татарстан, представители органов исполнительной власти Республики Татарстан, иных государственных органов, органов местного самоуправления, некоммерческих организаций. В состав Координационного совета при необходимости могут включаться представители иных субъектов патриотического воспитания.

4. Координационный совет ежегодно представляет Главе (Раису) Республики Татарстан отчет о реализации государственной политики в сфере патриотического воспитания граждан в Республике Татарстан.

Статья 9. **Участие граждан в мероприятиях в сфере патриотического воспитания**

В рамках реализации мероприятий по патриотическому воспитанию, повышению престижа военной службы, пропаганде защиты Отечества граждане вправе принимать участие в мероприятиях:

1) по сохранению и благоустройству воинских захоронений, мест погребения погибших при защите Отечества, установке надгробий, памятников, стел, обелисков, других мемориальных сооружений и объектов, увековечивающих память погибших;

2) по сохранению и обустройству отдельных территорий, исторически связанных с подвигами погибших при защите Отечества;

3) по проведению поисковой работы, направленной на выявление неизвестных воинских захоронений и непогребенных останков, установление имен погибших и пропавших без вести при защите Отечества;

4) по освещению в средствах массовой информации материалов о погибших при защите Отечества, организации и проведению памятных выставок, посвященных их подвигам;

5) в других мероприятиях в соответствии с федеральным законодательством и законодательством Республики Татарстан.

Статья 10. **Участие некоммерческих организаций в патриотическом воспитании**

1. Некоммерческие организации вправе:

1) организовывать и проводить мероприятия в сфере патриотического воспитания в соответствии с федеральным законодательством и законодательством Республики Татарстан;

2) участвовать в патриотическом воспитании в иных формах в соответствии с федеральным законодательством и законодательством Республики Татарстан.

2. Органы государственной власти Республики Татарстан содействуют некоммерческим организациям в укреплении культурных, духовно-нравственных основ патриотического воспитания посредством:

1) привлечения к участию в мероприятиях по патриотическому воспитанию в рамках государственных программ Республики Татарстан;

2) иных форм, предусмотренных федеральным законодательством и законодательством Республики Татарстан.

### Статья 11. **Финансовое обеспечение реализации государственной политики Республики Татарстан в сфере патриотического воспитания**

Финансовое обеспечение реализации государственной политики Республики Татарстан в сфере патриотического воспитания осуществляется за счет средств бюджета Республики Татарстан в пределах средств, предусмотренных законом Республики Татарстан о бюджете Республики Татарстан на соответствующий финансовый год и плановый период на указанные цели, а также иных источников, не запрещенных федеральным законодательством и законодательством Республики Татарстан.

### Статья 12. **Вступление в силу настоящего Закона**

Настоящий Закон вступает в силу со дня его официального опубликования.

Глава (Раис)
Республики Татарстан — Р.Н. Минниханов

Казань, Кремль
09 декабря 2023 года
№ 123-ЗРТ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# Татарстан Республикасында гражданнарга патриотик тәрбия бирү турында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2023 елның 23 ноябрендә
кабул ителде

## 1 статья. Әлеге Законның җайга салу предметы

1. Әлеге Закон Татарстан Республикасында гражданнарга патриотик тәрбия бирү (алга таба – патриотик тәрбия) өлкәсендә барлыкка килә торган мөнәсәбәтләрне җайга сала, патриотик тәрбиянең максатын, принципларын һәм бурычларын билгели.

2. Патриотик тәрбия турында Татарстан Республикасы законнары Россия Федерациясе Конституциясенең, Татарстан Республикасы Конституциясенең, федераль законнарның, Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларының тиешле нигезләмәләренә таяна һәм әлеге Законнан, Татарстан Республикасының башка законнарыннан һәм алар нигезендә кабул ителә торган Татарстан Республикасы норматив хокукый актларыннан тора.

## 2 статья. Әлеге Законда кулланыла торган төп төшенчәләр

1. Әлеге Закон максатларында патриотик тәрбия дигәндә Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының, җирле үзидарә органнарының, гражданнарга патриотик, шул исәптән хәрби-патриотик, тәрбия бирү өлкәсендә эшчәнлек алып баручы социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмаларның һәм патриотик тәрбиянең башка субъектларының гражданнарда патриотик аң, Туган илгә тугрылык, Ватанны саклау буенча граждан бурычын һәм конституциячел бурычларны үтәргә әзер булу, Ватан тарихына хөрмәт формалаштыру буенча максатчан эшчәнлеге аңлашыла.

2. Әлеге Законда кулланыла торган башка төшенчәләр федераль законнарда һәм Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән мәгънәләрендә кулланыла.

3 статья. **Патриотик тәрбиянең максаты, принциплары һәм бурычлары**

1. Патриотик тәрбиянең төп максаты гражданнарда рухи-әхлакый һәм социаль кыйммәтләр, гражданлыкның асылына туры килүне, конституциячел һәм хәрби бурычка тугрылык, җаваплылык һәм дисциплина формалаштырудан гыйбарәт.

2. Патриотик тәрбиянең принциплары:

1) гражданнар белән эшләүдә адреслы якын килү;

2) Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының патриотик тәрбиянең башка субъектлары белән үзара эшчәнлегенең системалы булуы һәм аны оештыру;

3) патриотик тәрбия эшчәнлеген оештырганда гражданнарның милли, этномәдәни, конфессиональ үзенчәлекләрен исәпкә алу;

4) гражданнарга патриотик тәрбия бирүдә өзлексезлек һәм дәвамчанлык;

5) патриотик тәрбиягә юнәлдерелгән чараларны гамәлгә ашыруның нәтиҗәләрен бәяләүдә ачыклык һәм мөстәкыйльлек;

6) гаиләне Россия җәмгыятенең нигезе итеп карауны формалаштыру.

3. Патриотик тәрбиянең төп бурычлары:

1) гражданнарга Россия Федерациясе Конституциясен, Татарстан Республикасы Конституциясен хөрмәт итү, законнарны үтәү рухында тәрбия бирү;

2) гражданнарда Россия Федерациясенең, Татарстан Республикасының мәдәни, тарихи үткәненә һәм гореф-гадәтләренә хөрмәт, Ватанга хезмәт итәргә, аны сакларга, граждан бурычын, һөнәри һәм хәрби бурычны намус белән үтәргә әзер булуны формалаштыру;

3) гражданнарда Россия Федерациясе дәүләт символлары, Татарстан Республикасы дәүләт символлары белән горурлану хисе һәм аларга карата хөрмәт уяту;

4) патриотик тәрбия системасын үстерү, дәүләт хезмәтенең абруен арттыру, гражданнарны Россия Федерациясе Кораллы Көчләре сафларында хезмәт итүгә әзерләүне камилләштерү;

5) ихтыярыйлык (волонтерлык) эшчәнлеген үстерү;

6) гражданнарда рухи-әхлакый үсешкә ихтыяҗ һәм өлкән буынга ихтирамлы мөнәсәбәт формалаштыру, буыннар арасында бәйләнеш булдыру, өлкәннәргә һәм якын кешеләргә кайгыртучанлык күрсәтү, гаилә институтын ныгыту һәм традицион гаилә кыйммәтләрен саклап калу;

7) халыклар арасында дуслык багланышларын үстерү, милләтара һәм конфессияара татулыкны тәэмин итү, экстремизм чагылышларына каршы тору өчен шартлар тудыру.

4 статья. **Патриотик тәрбия өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт сәясәте**

1. Патриотик тәрбия өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт сәясәте Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары тарафыннан җирле үзидарә органнары һәм патриотик тәрбиянең башка субъектлары белән үзара эшчәнлектә

башкарыла торган патриотик тәрбиягә юнәлдерелгән чаралар җыелмасыннан гыйбарәт.

2. Патриотик тәрбия өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру түбәндәге рәвешләрдә башкарыла:

1) патриотик тәрбия өлкәсендә норматив-хокукый җайга салу;

2) патриотик тәрбия системасын фәнни һәм методик тәэмин итү, патриотик тәрбия эшенең иң уңышлы һәм перспективалы рәвешләрен һәм ысулларын тарату;

3) патриотик тәрбия өлкәсендә ведомствоара үзара эшчәнлек һәм дәүләти-иҗтимагый партнерлыкны үстерү;

4) балаларга һәм яшьләргә патриотик тәрбия бирүне оештыру һәм уздыру, аларның Ватанга хезмәт итүгә мотивациясен, Ватан тарихын өйрәнү белән кызыксынуын арттыру буенча программалар, методикалар эшләү һәм аларны гамәлгә кертү;

5) патриотик тәрбия өлкәсендә белгечләр әзерләү;

6) патриотик тәрбияне мәгълүмати тәэмин итү;

7) тарихи, туган якны өйрәнү буенча һәм мемориаль музейлар булдыру һәм аларны саклау, Россия Федерациясенең хәрби дан көннәрен һәм истәлекле даталарын, Татарстан Республикасының истәлекле даталарын мәңгеләштерүче һәйкәлләр, обелисклар, стелалар, башка мемориаль корылмалар, объектлар урнаштыру һәм аларны төзекләндерү, күргәзмәләр оештыру, хәрби дан урыннарында мемориаль билгеләр урнаштыру;

8) Татарстан Республикасының тарихи урыннары буйлап туристик маршрутлар эшләү;

9) хәрби хезмәткә чакырылу яшенә җитеп килүче һәм хәрби хезмәткә чакырылу яшенә җиткән гражданнарның Россия Федерациясе Кораллы Көчләре сафларында хезмәт итүгә әзерлек узуы өчен шартлар тәэмин итү;

10) мәгариф оешмаларының ветераннар оешмалары, сугышчан дан музейлары, шулай ук Бөек Ватан сугышы, хәрби хәрәкәтләр, хәрби хезмәт ветераннары белән үзара эшчәнлеге системасын оештыру һәм үстерү;

11) патриотик юнәлештәге әсәрләр иҗат итүдә сәнгать һәм әдәбият әһелләренә ярдәм күрсәтү;

12) Россия Федерациясенең хәрби дан көннәренә һәм истәлекле даталарына, Татарстан Республикасының истәлекле даталарына багышланган тантаналы һәм истәлекле чаралар оештыру һәм уздыру;

13) патриотик тәрбия өлкәсендәге иҗтимагый проектларга ярдәм итү.

5 статья. **Патриотик тәрбия субъектлары**

Патриотик тәрбия субъектлары:

1) Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары һәм аларга ведомство буйсынуындагы оешмалар;

2) җирле үзидарә органнары һәм аларга ведомство буйсынуындагы оешмалар;

3) мәгариф оешмалары һәм фәнни оешмалар;

4) дәүләт һәм муниципаль мәдәният, сәнгать һәм кинематография оешмалары;

5) яшьләр сәясәте, физик культура һәм спорт өлкәсендәге дәүләт оешмалары һәм муниципаль оешмалар;

6) гражданнарга патриотик, шул исәптән хәрби-патриотик, тәрбия бирү өлкәсендә эшчәнлек алып баручы социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмалар (алга таба – коммерциягә карамаган оешмалар);

7) иҗтимагый-дәүләти оешмалар, ветераннар оешмалары, эзләү берләшмәләре һәм патриотик юнәлештәге башка иҗтимагый берләшмәләр;

8) дәүләт һәм муниципаль массакүләм мәгълүмат чаралары;

9) патриотик тәрбия үзәкләре;

10) абруе, патриотизмы, граждан, һөнәри һәм хәрби бурычка тугрылыгы башкалар өчен охшарга тырышу үрнәге һәм өлгесе булган Россия Федерациясе гражданнары.

6 статья. **Патриотик тәрбия өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары вәкаләтләре**

1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

1) патриотик тәрбия өлкәсендә мөнәсәбәтләрне законнар белән җайга салу;

2) патриотик тәрбия өлкәсендә Татарстан Республикасы законнарын үтәүне һәм гамәлгә ашыруны тикшереп тору;

3) федераль законнарда һәм Татарстан Республикасы законнарында каралган башка вәкаләтләрне башкару.

2. Татарстан Республикасы Рәисе вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

1) патриотик тәрбия өлкәсендә норматив хокукый актлар чыгару;

2) Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарының башка дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм патриотик тәрбиянең башка субъектлары белән эшчәнлеген координацияләүне тәэмин итү;

3) Татарстан Республикасында гражданнарга патриотик тәрбия бирү буенча координация советы (алга таба – Координация советы) төзү, Координация советы турындагы нигезләмәне һәм аның составын раслау;

4) федераль законнарда һәм Татарстан Республикасы законнарында каралган башка вәкаләтләрне башкару.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

1) патриотик тәрбия өлкәсендә норматив хокукый актлар чыгару;

2) патриотик тәрбия өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт сәясәтенең төп юнәлешләрен билгеләү;

3) патриотик тәрбия өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт программаларын раслау;

4) патриотик тәрбия өлкәсендә җирле үзидарә органнарына методик ярдәм күрсәтүне оештыру;

5) патриотик тәрбия өлкәсендә коммерциягә карамаган оешмаларга булышлык һәм ярдәм күрсәтү;

6) федераль законнарда һәм Татарстан Республикасы законнарында каралган башка вәкаләтләрне башкару.

4. Мәгариф өлкәсендә дәүләт идарәсен башкаручы Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

1) мәгариф оешмаларында укучыларга патриотик тәрбия бирүгә юнәлдерелгән чараларны гамәлгә ашыру;

2) патриотик тәрбия өлкәсендә чараларны гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча патриотик юнәлештәге иҗтимагый берләшмәләр белән үзара эшчәнлек;

3) укучыларда патриотик аң формалаштыруга юнәлдерелгән чаралар оештыру һәм уздыру;

4) патриотик тәрбия буенча укучылар арасында олимпиадалар һәм конкурслар оештыру һәм уздыру;

5) гомуми белем бирү оешмаларында укучыларның хәрби хезмәт нигезләре буенча башлангыч белемнәр алуын тәэмин итү;

6) урта гомуми белем бирү яисә урта һөнәри белем бирү уку-укыту программаларын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларында укучыларның хәрби хезмәт нигезләре буенча әзерлек үтүен оештыру;

7) мәгариф оешмаларында туган якны өйрәнү хәрәкәте, Татарстан Республикасының тарихи-мәдәни мирасын өйрәнү буенча тикшеренү, мәдәни-агарту эшләре үсешенә булышлык күрсәтү;

8) федераль законнарда һәм Татарстан Республикасы законнарында каралган башка вәкаләтләрне башкару.

5. Яшьләр сәясәте өлкәсендә дәүләт идарәсен башкаручы Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

1) яшьләрнең патриотик, сәяси һәм граждан активлыгы, җитлегүе дәрәҗәсен арттыру;

2) граждан-патриотик тәрбиянең яшьләрдә дөрес кыйммәтләр формалаштырудагы ролен көчәйтү;

3) яшьләргә патриотик тәрбия бирү системасын, яшьләр мохитендә милли үзаңны һәм толерантлыкны үстерү;

4) Татарстан Республикасында ихтыярыйлык (волонтерлык) хәрәкәте үсешенә булышлык күрсәтү;

5) патриотик юнәлештәге чаралар оештыру һәм уздыру;

6) федераль законнарда һәм Татарстан Республикасы законнарында каралган башка вәкаләтләрне башкару.

6. Мәдәният, сәнгать, кинематография өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыручы һәм мөнәсәбәтләрне җайга салучы Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

1) Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы тарихи вакыйгаларына һәм истәлекле даталарына багышланган чаралар уздыруны оештыру;

2) патриотик тәрбия өлкәсендә фестивальләр, конкурслар, күргәзмәләр, кинофестивальләр, иҗади семинарлар, тамашачылар белән тематик очрашулар һәм башка чаралар оештыру, шул исәптән аларны уздыру тәртибен билгеләү;

3) патриотик тәрбия өлкәсендә Россиянеке һәм халыкара булган күргәзмәләрдә, конференцияләрдә, фестивальләрдә һәм конкурсларда катнашу, патриотик темага күргәзмәләр оештыру;

4) Ватанны саклаучы (саклаучылар) һәм аның (аларның) кылган батырлыклары истәлеген мәңгеләштерүгә багышланган иң яхшы музейга (музей экспозициясенә) конкурс уздыру;

5) федераль законнарда һәм Татарстан Республикасы законнарында каралган башка вәкаләтләрне башкару.

7. Физик культура һәм спорт өлкәсендә дәүләт идарәсен һәм эшчәнлекне гамәлгә ашыручы Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

1) Татарстан Республикасының барлык яшь төркемнәрендәге халкының физик әзерлек дәрәҗәсен арттыру максатларында физкультура, савыктыру спорт чаралары оештыру;

2) хәрби-гамәли спорт төрләрен пропагандалау;

3) Татарстан Республикасының барлык яшь төркемнәрендәге халкы өчен «Хезмәткә һәм оборонага әзер» бөтенроссия физкультура-спорт комплексын (ГТО) тапшыруны оештыру;

4) федераль законнарда һәм Татарстан Республикасы законнарында каралган башка вәкаләтләрне башкару.

8. Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә дәүләт идарәсе мәсьәләләре буенча вәкаләтләр башкаручы Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

1) патриотик тәрбия өлкәсендәге чараларны массакүләм мәгълүмат чараларында яктыртуны оештыру;

2) патриотизм формалаштыруга булыша торган китаплар һәм басма продукция нәшер итүне һәм таратуны оештыру;

3) патриотик темага журналистлар конкурслары, иҗади конкурслар оештыру һәм уздыру;

4) федераль законнарда һәм Татарстан Республикасы законнарында каралган башка вәкаләтләрне башкару.

9. Туризм өлкәсендә дәүләт идарәсе функцияләрен башкаручы Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

1) Татарстан Республикасының тарихи урыннары буйлап туристик маршрутлар эшләүдә булышлык күрсәтү;

2) федераль законнарда һәм Татарстан Республикасы законнарында каралган башка вәкаләтләрне башкару.

7 статья. **Патриотик тәрбиядә җирле үзидарә органнарының катнашуы**

1. Җирле үзидарә органнары патриотик тәрбия эшчәнлегендә федераль законнарда билгеләнгән вәкаләтләр чикләрендә катнашырга хокуклы.

2. Җирле үзидарә органнары патриотик тәрбия өлкәсендәге чараларны үз эченә алган муниципаль программалар расларга хокуклы.

8 статья. **Координация советы**

1. Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарының, башка дәүләт органнарының, җирле үзидарә органнарының, шулай ук патриотик тәрбиянең башка субъектларының үзара эшчәнлеген камилләштерү максатларында Координация советы төзелә.

2. Координация советы Татарстан Республикасы Рәисе тарафыннан төзелә һәм консультатив һәм киңәшмә орган булып тора.

3. Координация советы составына Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары, Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары, башка дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, коммерциягә карамаган оешмалар вәкилләре кертелә. Координация советы составына, кирәк булганда, патриотик тәрбиянең башка субъектлары вәкилләре дә кертелергә мөмкин.

4. Координация советы ел саен Татарстан Республикасы Рәисенә Татарстан Республикасында гражданнарга патриотик тәрбия бирү өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру турында хисап тапшыра.

9 статья. **Патриотик тәрбия өлкәсендәге чараларда гражданнарның катнашуы**

Патриотик тәрбия, хәрби хезмәтнең абруен арттыру, Ватанны саклауны пропагандалау чараларын гамәлгә ашыру кысаларында гражданнар түбәндәге чараларда катнашырга хокуклы:

1) хәрби каберлекләрне, Ватанны саклаганда һәлак булганнар күмелгән урыннарны саклау һәм төзекләндерү, һәлак булганнарның истәлеген мәңгеләштерүче кабер ташлары, һәйкәлләр, стелалар, обелисклар, башка мемориаль корылмалар һәм объектлар урнаштыру;

2) Ватанны саклаганда һәлак булганнарның батырлыклары белән тарихи бәйләнеше булган аерым территорияләрне саклау һәм төзекләндерү;

3) билгесез хәрби каберлекләрне һәм җирләнмәгән мәетләрне табуга, Ватанны саклаганда һәлак булганнарның һәм хәбәрсез югалганнарның исемнәрен ачыклауга юнәлдерелгән эзләү эшен уздыру;

4) Ватанны саклаганда һәлак булганнар турындагы материалларны массакүләм мәгълүмат чараларында яктырту, аларның батырлыгына багышланган истәлекле күргәзмәләр оештыру һәм уздыру;

5) федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә башка чаралар.

10 статья. **Патриотик тәрбиядә коммерциягә карамаган оешмаларның катнашуы**

1. Коммерциягә карамаган оешмалар түбәндәгеләргә хокуклы:

1) патриотик тәрбия өлкәсендә чараларны федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә оештырырга һәм уздырырга;

2) патриотик тәрбия эшендә федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә башка рәвешләрдә катнашырга.

2. Коммерциягә карамаган оешмаларга патриотик тәрбиянең мәдәни, рухи-әхлакый нигезләрен ныгытуда Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары түбәндәгечә ярдәм күрсәтә:

1) Татарстан Республикасы дәүләт программалары кысаларындагы патриотик тәрбия чараларында катнашуга җәлеп итү юлы белән;

2) федераль законнарда һәм Татарстан Республикасы законнарында каралган башка рәвешләрдә.

**11 статья. Патриотик тәрбия өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыруны финанс белән тәэмин итү**

Патриотик тәрбия өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыруны финанс белән тәэмин итү тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законында бу максатларга каралган акчалар кысаларында Татарстан Республикасы бюджеты акчалары, шулай ук федераль законнарда һәм Татарстан Республикасы законнарында тыелмаган башка чыганаклар исәбеннән гамәлгә ашырыла.

**12 статья. Әлеге Законның үз көченә керүе**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе — Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2023 ел, 09 декабрь
№ 123-ТРЗ